**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**III чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йортТел. 3-44-44,факс3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**III созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/.3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 06.08.2019г

**РЕШЕНИЕ**
№39-01

«Актаныш муницпаль районы авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итүне яхшырту» муниципаль программасы турында

Россия Федерациясенең 2003 нче елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131 санлы Федераль Законының 1 нче пунктындагы 4 нче пунктчасы, 1999 елның 30 мартында кабул ителгән 52 санлы "Халыкны санитар-эпидемиологик иминлеге турында", 2011 елның 7 декабрендә кабул ителгән 416 санлы "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында" Федераль Законнары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы карар итте:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең докладын игътибарга алырга.
2. Авыл җирлекләренә авыл халкын куркынычсызлык һәм зыянсызлык таләпләренә туры килә торган чиста су белән тәэмин итү максатыннан, санитар-эпидемиология кагыйдәләре белән билгеләнгән «Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итүне яхшырту» муниципаль программасын расларга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында веб-адрес буенча игълан итәргә http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru Интернетның мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Ф.Галимҗановага йөкләргә.

**Совет рәисе** **Э.Н.Фәттахов**